| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОКУВАКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ КУАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

2021 елны “03“ декабре — Иске Куак — № 25

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 3 августындагы 14 номерлы Карары белән расланган Агач, куак кисүгә, кронлаштыру, утырту һәм күчереп утырту, газонны сүтү өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең яңа редакциядәге административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең электрон формасында күрсәтүгә таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 18 сентябрендәге 1574 номерлы Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 3 августындагы 14 номерлы Карары белән расланган Агач, куак кисүгә, кронлаштыру, утырту һәм күчереп утырту, газонны сүтү өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең яңа редакциядә административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.16.1 пунктны пунктчалар белән тулыландырырга:

«ж) органга (оешмага) кабул итүгә язылу, хезмәт күрсәтү турында запрос бирү өчен (алга таба-запрос) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба-күпфункцияле үзәк), шулай ук хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган очракларда, әлеге запросныкүрсәтелгән кабул итүгә бер үк вакытта язылып, бирү мөмкинлеге бар; (үз көченә 2022 елның 22 мартыннан керә)

з) муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантын билгеләү максатларында, мөрәҗәгать итүченең билгеләренә туры килә торган анкеталаштыру (мөрәҗәгать итүчегә сораулар исемелеген һәм аларга тулы җаваплар вариантлары исемлеген күрсәтү);

и) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында каралган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантын күрсәтү.».

2. Әлеге Карарны Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы — И.Н Сушкова